ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА УРУССУ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы,
Пушкин урамы, 38

Тел.: 8(85593)2-42-17, e-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 04 » 12 2024 г. №_20_

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә 2025 елга муниципаль контроль буенча закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ санлы Федераль закон, «Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау программасын контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 25 июнендәге 990 санлы Карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советының 2020 елның 28 апрелендәге 5 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Башкарма комитеты к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә 2025 елга муниципаль контроль буенча закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалауның кушымтада бирелә торган программасын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе" муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы

А.Н. Захаров

шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
Башкарма комитетының
_04.12.2024 ел № __20____
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә 2025 елга муниципаль контроль буенча закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасы

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә 2025 елга муниципаль контроль буенча закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалауның әлеге программасы (алга таба - Программа) оешмалар һәм гражданнар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең намуслы үтәлешен стимуллаштыру, мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яисә) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерергә мөмкин булган шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү, контрольдә тотылучы затларга мәҗбүри таләпләрне җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында хәбәрдарлыкны арттыру максатларында эшләнгән.

Әлеге Программа шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тарафыннан эшләнгән һәм үтәлергә тиеш.

1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның агымдагы торышына анализ, контроль органының профилактика эшчәнлегенең агымдагы үсешен тасвирлау, Программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблемаларга характеристика бирү

1.1. Муниципаль контроль төре: төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль.

1.2. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 23.12.2019 елның № 23 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясендә социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү муниципаль контроль предметы булып тора.

Контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларны үтәү дә муниципаль контроль предметы булып тора.

## 2. Программаны гамәлгә ашыруның максатлары һәм бурычлары

2.1. Профилактика эшенең максатлары булып түбәндәгеләр тора:

1) Барлык тикшереп торылучы затларның мәҗбүри таләпләрне намуслы үтәвен стимуллаштыру;

2) мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яисә) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерергә сәләтле шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү;

3) контрольдә тотылучы затларга мәҗбүри таләпләр җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында хәбәрдарлыкны арттыру;

4) контрольдә тотылучы затларның мәҗбүри таләпләрне бозу ихтималына китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерүне дә кертеп, аларны бозуларын кисәтү;

5) тикшереп торылучы затларга административ йөкләнешне киметү;

6) закон белән саклана торган кыйммәтләргә китерелә торган зыян күләмен киметү.

2.2. Профилактика эшенең бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау системасын ныгыту;

2) мәҗбүри таләпләрне бозуларга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау, мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар әзерләү;

3) карала торган хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә оешмаларның һәм гражданнарның хокукый аңын һәм хокукый культурасын күтәрү.

Контроль төре турындагы нигезләмәдә намуслы контрольдә тотылучы затларны матди булмаган бүләкләүгә юнәлдерелгән чаралар билгеләнмәгән, димәк, программада намуслылыкны стимуллаштыру чаралары каралмаган.

Контроль төре турындагы нигезләмәдә мәҗбүри таләпләрне үтәүне мөстәкыйль бәяләү (үз-үзеңне тикшерү) каралмаган, димәк, программада автоматлаштырылган режимда үз-үзеңне тикшерү ысуллары билгеләнмәгән («Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ санлы Федераль законның 51 маддәсенең 1 өлеше).

## 3. Профилактик чаралар исемлеге, аларны үткәрү сроклары (ешлыгы)

| № т/б | Чараның исеме | Чараны гамәлгә ашыру срогы | Җаваплы вазыйфаи зат |
|---|---|---|---|
| 1. | Мәгълүмат бирү. Мәгълүмат бирү мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча Башкарма комитет тарафыннан тиешле белешмәләрне Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтына урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла | Даими рәвештә | Вазыйфаи бурычларына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру керә торган Башкарма комитет белгече |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Хокук куллану практикасын гомумиләштерү.<br>Хокук куллану практикасын гомумиләштерү үткәрелгән контроль чаралар һәм аларның нәтиҗәләре турында белешмәләрне җыю һәм анализлау юлы белән Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла.<br>Хокук куллану практикасын гомумиләштерү йомгаклары буенча Башкарма комитет муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган доклад әзерли, ул контроль органы җитәкчесе тарафыннан раслана | Ел саен хокук куллану практикасын гомумиләштерү елыннан соң килүче елның 30 гыйнварыннан да соңга калмыйча | Вазыйфаи бурычларына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру керә торган Башкарма комитет белгече |
| 3. | Кисәтү игълан итү.<br>Мәҗбүри таләпләрне бозу турында Башкарма комитетта белешмәләр булган очракта һәм (яисә) мәҗбүри таләпләрне бозуның закон белән саклана торган мәнфәгатьләргә зыян (зарар) китерүе турында белешмәләр расланмаган очракта, контрольдә тотылучы затка кисәтү игълан ителә | Законнарда каралган нигезләр барлыкка килүгә карап | Вазыйфаи бурычларына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру керә торган Башкарма комитет белгече |
| 4. | Консультацияләү.<br>Консультацияләр телдән яисә язма рәвештә телефон аша, видео-конференц-элемтә аша, шәхсән кабул иткәндә, профилактик чара, контроль (күзәтчелек) чарасы барышында башкарыла. | Контрольдәге затлар һәм аларның вәкилләре мөрәҗәгатьләре буенча даими рәвештә | Вазыйфаи бурычларына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру керә торган Башкарма комитет белгече |
| 5. | Профилактик визит | Елына бер тапкыр | Вазыйфаи бурычларына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру керә торган Башкарма комитет белгече муниципального контроля |

## 4. Программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре

| № т/б | Күрсәткеч исеме | Күләме |
|---|---|---|
| 1. | «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 2021 елның 31 июлендәге 248-ФЗ санлы Федераль законның 46 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге сайтында урнаштырылган мәгълүматның тулылыгы | 100% |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган докладны раслау, аны бастырып чыгару | Башкарылган / Башкарылмаган |
| 3. | Әзерләнә торган мәҗбүри таләпләрне бозулар яисә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында расланган белешмәләр булган мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча һәм мәҗбүри таләпләрне бозуның закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүе йә закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы тудыруы турында расланган мәгълүматлар булмаган очракта кисәтүләр өлеше ( % ) | 20% һәм аннан күбрәк |
| 4. | Консультация сорап мөрәҗәгать иткән затларның гомуми санында консультация бирүдән канәгать булган затлар өлеше | 100% |